**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның 2 июнендәге 1876 номерлы карары**

**Казан шәһәренең Совет районында**
**ачык сервитут билгеләү турында**

1. Әлеге карарга 1, 2 номерлы кушымталар нигезендә ачык сервитут билгеләргә:

1.1. билгеләнә торган ачык сервитут характеристикасы:

- йогынты ясала торган өлкә мәйданы – 9 кв.м;
- хокуклар чикләнә торган җир кишәрлегенең кадастр номеры – 16:50:150106:63;
- урнашу урыны: Казан шәһәре, Совет районы, Вербная урамы;
- билгеләү максаты: су белән тәэмин итү һәм канализация челтәрләреннән файдалану, аларны ремонтлау, насос җайланмасы булган кое;
- билгеләү вакыты: 49 ел;

1.2. гариза бирүче: «Водоканал» муниципаль унитар предприятиесе;

1.3. билгеләү өчен нигезләр: гариза бирүче мөрәҗәгате, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль закон, Россия Федерациясе Җир кодексының 39.37 статьясының 1 пункты, Россия Федерациясе Җир кодексының 23 статьясы, Россия Федерациясе Җир кодексының V.7 бүлеге, 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы «Су белән тәэмин итү һәм су чыгару турында»гы федераль закон.

2. Җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалану төре нигезендә файдалану мөмкин булмаячак яки сервитутны гамәлгә ашыру белән бәйле рәвештә сизелерлек кыенлашачак вакыт әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән ачык сервитут вакытына туры килә дип билгеләргә.

3. «Казанны үстерү институты» муниципаль бюджет учреждениесенә әлеге карарга 1, 2 номерлы кушымталар нигезендә чикләрдә ачык сервитутның йогынты ясау өлкәсе турында тиешле мәгълүмат кертү һәм ачык сервитутны дәүләт теркәвенә алу өчен Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә мөрәҗәгать итүне йөкләргә.

4. Әлеге карарга 2 номерлы кушымтадан кала (хезмәт урынында файдалана торган материал), әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

5. Әлеге карар «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) рәсми басылып чыкканнан соң гамәлгә керә дип билгеләргә.


6. «Водоканал» муниципаль унитар предприятиесенә әлеге карарның 1.1 пунктчасында күрсәтелгән җир кишәрлеген, урнаштыру өчен ачык сервитут билгеләнгән инженерлык корылмасын төзү, капиталь яки агымдагы ремонтлау, реконструкцияләү, эксплуатацияләү, консервацияләү, сүтү эшләре тәмамланганнан соң яисә Россия Федерациясе Җир кодексының 39.37 статьясындагы 2, 5 пунктлар белән каралган максатларда ачык сервитут билгеләнгән очракларда – җир кишәрлегендә тәэмин итү өчен ачык сервитут билгеләнгән эшчәнлек тәмамланганнан соң өч айдан да соңга калмыйча, рөхсәт ителгән файдалану төре нигезендә файдалану өчен яраклы хәлгә китерүне тәкъдим итәргә.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитетының Җир һәм милек мөнәсәбәтләре комитеты рәисе Р.Г.Галәветдиновка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2026 елның 2 июнендәге
1876 номерлы карарына
1 номерлы кушымта

## Ачык сервитут йогынтысы өлкәсе чикләре




| | |
|---|---|
| Масштаб: 1:30<br>Координаталар системасы: МСК-16 | |
| Шартлы билгеләр: | |
| 1 | Яңа ясалган характерлы нокта |
| | Җир кишәрлекләре |
| 16:50:150106 | кадастр кварталы |
| 16:50:150106:63 | хокуклар чикләнә торган җир кишәрлегенең кадастр номеры |